ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ КИҢӘШЧЕСЕ

# Рәхмәт хаты

*Хөрмәтле Шәмил Габдулхай улы!*

*«Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-шәһәре» дигән уникаль проектны гамәлгә ашыруда катнашуыгыз өчен Сезгә ихлас рәхмәт сүзләремне җиткерәм.*

*Сезнең «Яңарыш» фондына керткән өлешегез – киң күңеллелек, рухи юмартлык һәм затлылыкның асыл үрнәге ул. Чал тарихыбызның чын кыйммәтен һәм милли-мәдәни хәзинәләребезнең кадерен белүчеләр тырышлыгы ярдәмендә истәлек-ядкарьләребез үзләренең элеккеге бөеклеген яңартыр, дип ышанам.*

*Татарстан һәм Россия Федерациясе өчен гаять әһәмиятле әлеге тарихи бурычны уртак көч һәм тырышлык белән уңышлы хәл итәчәгебезгә шигем юк.*

*Матди ярдәмегез өчен рәхмәт йөзеннән Сезнең оешмагыз Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика Фондының хәйриячеләр китабының I томына кертелде. Хәйриячеләр исемлеге (акча кереме тәртибендә) 34нче бит, 32нчы сан астында.*

*Сезнең барлык игелекле эшләрегездә уңышлар юлдаш булсын.*

***Татарстан Республикасы***
***тарихи һәм мәдәни***
***истәлекләрен торгызу***
***Республика Фондының***
***Попечительләр Советы рәисе***

***М.Ш. Шәймиев***